**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**
**423962, Ютазы авылы,**
**Дмитров урамы, 2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**423962, с. Ютаза,**
**ул. Дмитрова, д.2**
**тел. 4-00-91**
**факс: 8 (85593) 4-00-93**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 5** **«07» февраль 2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

2022 елның 15 ноябрьндәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Каркале торак пунктында халык җыенының 1 санлы карарын,

2022 елның 16 ноябрьндәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы Малиновка торак пунктында халык җыенының 2 санлы карарын,

2022 елның 16 ноябрьндәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Алма-Ата торак пунктында халык җыенының 3 санлы карарын,

2022 елның 16 ноябрьндәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Кымыз шифаханэсе торак пунктында халык җыенының 4 санлы карарын,

2022 елның 16 ноябрьндәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ик торак пунктында халык җыенының 5 санлы карарын,

2022 елның 18 ноябрьндәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында халык җыенының 6 санлы карарын гамәлгә ашыру максатларында

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл

җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә веб - адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы
Вазифаларын башкыручы Н.Ф.Заляев

Ютазы авыл җирлегенең<br>2023 елның 07 февральндагы<br>5санлы<br>карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Ютазы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, тавыш бирүдә катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2023 елның 22 гыйнварыннан 2023 елның 25 мартына кадәр үзара салым акчалары түләү башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булган очракта, ә аларга түбәндәгеләр керә ала:

а) торган урын буенча озак яшәмәү,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Димтамак авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр акчаны физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, Димтамак авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша күчерелә.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Ютазы авыл җирлегенең
2023 елның 07 февральндагы
5 санлы карарына 2 кушымта

Ютазы авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ______ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________________
Адрес: ___________________________________________________________________
Халык җыены карары нигезендә торак пунктта_____________________Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча сезгә _________ _ _ _ _ кадәр халык җыены чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләүне түбәндәге реквизитлар буенча башкарырга кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү **2022 ел өчен гражданнарның үзара салым акчасы.**

Җитәкче ____________________________________________________________
П.У. (имза) (имзаны раслау)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Ютазы авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында № _________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(*муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ______________________________________________________
Адрес: ___________________________________________________________________
«__» _______________ 20__ елны _________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетында, мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм кала.*